ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2022 Олы Кайбыч ав. № 371

Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче, белем алган 15 - 21 яшьтәге халык өлеше» исәбе өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче, белем алган 15 - 21 яшьтәге халык өлеше» исәбе өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын кушымтад каралганча расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» 08. 2022
№371 карарына кушымта

**Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче, белем алган 15 - 21 яшьтәге халык өлеше» исәбе өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ регламентны җайга салу предметы

Әлеге хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче, белем алган 15 - 21 яшьтәге халык өлеше» исәбе өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары, «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче, белем алган 15 - 21 яшьтәге халык өлеше» исәбе өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау тәртибен билгели (алга таба - декомпозицияләнгән күрсәткеч):

төп гомуми белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны;

урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны;

югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьтәге укучылар саны.

Кайбыч муниципаль районында декомпозия күрсәткечләрен җыйган һәм мониторинглаган өчен җаваплылык үзәге - «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге).

1.2. Белешмә мәгълүмат.

Әлеге регламент максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче, Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләрне исәпләү методикасында билгеләнгән, «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керүче «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткечен исәпкә алу методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла. Әлеге терминнар «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән билгеләнгән.

## 1. Исәп-хисап стандарты, җыю тәртибе һәм белешмәләр бирү

Декомпозияләнгән ярдәмче күрсәткечләрне исәпләү өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

төп гомуми белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны;

урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны;

югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьтәге укучылар саны.

Мәгариф бүлегенең җаваплы хезмәткәре хисап чорында төп гомуми белем бирү программалары буенча хезмәт күрсәтүче оешмалардан, урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча, югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча югарыда күрсәтелгән мәгълүматлар җыюны гамәлгә ашыра.

Муниципаль район (шәһәр округы) буенча җыелма мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән бирелә.

## 1. Мәгълүматлар бирүнең составы, срогы һәм рәвеше

1.1. Төп гомуми белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешмалар тарафыннан мәгълүматлар бирү формасы 1 нче Таблицада китерелгән.

1нче таблица.

Төп гомуми белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны

| т/б № | Төп гомуми белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма аталышы | Үлчәү берәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | Төп гомуми белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

1.2. Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешмалар тарафыннан мәгълүматлар бирү формасы 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица.

Урта  һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны

| № т/б | Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешма исеме | Үлчәү бердәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | Урта һөнәри белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьлек укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

1.3. Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешмалар тарафыннан мәгълүматлар бирү формасы 3 нче таблицада китерелгән.

3нче таблица.

Югары  белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьтәге укучылар саны

| т/б № | Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча хезмәтләр күрсәтүче оешма исеме | Үлчәү бердәмлеге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | Югары белем бирүнең төп һөнәри белем бирү программалары буенча 15 - 21 яшьтәге укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |